# ТЕЛ АЧКЫЧЫ

Сүз һәм туган тел турында шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Т33

Т ө з ү ч е - м ө х ә р р и р е
*Эльвира Кәлимуллина*

Т33 Тел ачкычы : сүз һәм туган тел турында шигырьләр / төз. Э.Кәлимуллина. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 95 б.
ISBN 978-5-298-01904-0

Җыентыкта сүз һәм туган тел турында шигырьләр тупланды. Шулай ук шагыйрьләр хакында кыскача биографик мәгълүмат та бирелде. Әлеге шигырьләр телебезне яратучы, хөрмәт итүче укучыларны битараф калдырмас.
Китап мәктәп яшендәге балаларга, укытучыларга, тәрбиячеләргә һәм ата-аналарга адреслана.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01904-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Кәлимуллина Э.Т., төзү, 2010

## *Йосыф Баласагунлы*

*(1016 һәм 1021 еллар аралыгы – 1070 елдан соң)*

Караханилар дәүләтенең Баласагун каласында (ул Чу елгасы үзәнлегендәге хәзерге Токмак шәһәре тирәсендә урнашкан була) дөньяга килә.

Вафат булган урыны һәм төгәл вакыты билгеле түгел.

### КОТАДГУ БЕЛЕК

*(өзек)*

...Укушка, белегкә бу телмәчи тел,
Йарутгачы ирне йорук телен, бел.
[Укуга, белемгә тылмач ул бу тел,
Кешене нурлаган нәрсә тел ул – бел.]

Кешег тел агырлар, булыр кот кеше,
Кешег тел очызлар, йарыр ир башы.
[Кешене тел хөрмәтле, бәхетле итәр,
Кешене тел очсызлар, башын ярыр.]

Тел арслан торыр, күр, ишекдә йатар,
Әйа эвлүг арсык – башыңны йийәр.
[Тел ишектә (читлектә) яткан арслан кебек ул,
Аның белән бераз гына саксызлык башыңны ашар.]

## *Мөхәммәдьяр*

*(1497–1549)*

Казан ханлыгы чорында иҗат иткән күренекле татар шагыйре. «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге»), «Нуры содур» («Күңелләр нуры») исемле ике поэмасы һәм «Нәсыйхәт» шигыре билгеле.

Казан делегациясе составында тылмач булып Мәскәүгә килгәч, Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан Муром шәһәре тирәсендә үтерелә.

### НУРЫ СОДУР

*(өзек)*

...Адәм угълының вөҗүде эчрә[1], бел,
Бер тылсым, бер әл-гаҗәб[2] ирер бу тел.

...Ул тылсым ачкычы берлә әчелер,
Ни ки телдин чыкты – ул башка килер.

...Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килер,
Адәмигә нә ки кыйлса, тел кыйлыр.

---

[1] *Вөҗүде эчрә* – тормышында.
[2] *Әл-гаҗәб* – гаҗәеп.

## *Дәрдемәнд*

*(1859–1921)*

Башкортстан Республикасының Мәләвез районы Җиргән авылында дөньяга килә.

Баймак районы Моллакай авылы мәдрәсәсендә белем ала.

Орск шәһәрендә вафат була.

* * *

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак – наданлыктан әсәрдер[1].

* * *

Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син – урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифең:
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?..

* * *

Урамнан һәм базардан чүплә сүзне,
Алар бетмәс борын, барма еракка!
Тупас та булса тел – илнең колагы,
Уеңны уйдырып сал шул колакка.

---

[1] *Наданлыктан әсәрдер* – наданлык билгеседер.

## *Сәгыйть Рәмиев*

*(1880–1926)*

Башкортстан Республикасының Күгәрчен районы Акман (Ибрай) авылында туа.

Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый.

Уфа шәһәрендә вафат була.

### СҮЗЕМ ҺӘМ ҮЗЕМ

*(өзек)*

...Сүз көчле ул, мәгънәле ул, сирәк булса,
Тыңлаучы да сүз аңлаучы зирәк булса...

## *Мәҗит Гафури*

*(1880–1934)*

Башкортстан Республикасының Гафури районы Җилем-Каран авылында дөньяга килә.

Троицк шәһәрендәге «Рәсүлия», Казан, Уфа шәһәрләрендәге «Мөхәммәдия», «Галия» мәдрәсәләрендә белем ала.

Башкортстан Республикасының халык шагыйре (1923).

Уфа шәһәрендә вафат була.

### АНА ТЕЛЕ

Үз ана телем – минем өчен матур, иң тәмле тел,
Үз телем – үз әйберем булган өчен ярата күңел.

Шул ана теле белән мин мәкъсудымны аңлатам,
Шул ана теле белән «балам» диләр анам-атам.

Шул тел аркылы иман, уку, язуны үгрәнәм,
Шул тел аркылы укып-белеп булырмын чын адәм.

Мин бала чактук «әти-әни» дидем шул тел белән,
Һәм дә әнкәм дә миңа «бәбкәм» дигән шул тел белән.

Әле дә шул тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм,
Шул татар теле белән көйлим, берәр көй көйләсәм.

Һәрвакыт шул тел белән язган матур китап укыйм,
Һәрвакыт шул тел белән тарих укыйм, хисап укыйм.

## *Миргазиз Укмаси*

*(1884–1948)*

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылында туа.

Казан шәһәрендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый.

Югары Осланда вафат була.

### МИЛЛИ ТЕЛ

Милли тел – күрке халыкның, бетми милли телләләр,
Күп яшәргә дәртле милләт халкы милли тел биләр.

Хәтфәләнгәч, җир яшәргәч, бик матур сахра, болын,
Әмма бакча тагы башка, күп чәчәк вә гөлләләр.

Бик бизәнгән төрле төстә төрле кошлар күп, ләкин
Таң ярып сайраучы былбылга тиң килмиләр.

Яхшы милли телле – милләт, милли тел – милләт җаны,
Изге хисне, милли гадәтне дә милли тел сөйләр.

## *Габдулла Тукай*

*(1886–1913)*

Татарстан Республикасының Арча районы Кушлавыч авылында туа.

Уральск шәһәрендәге «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә белем ала.

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

## *Хәсән Туфан*

*(1900–1981)*

Татарстан Республикасының Аксубай районы Иске Кармәт авылында дөньяга килә.

Уфа шәһәрендәге «Галия» мәдрәсәсендә укый.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1966).

Казанда вафат була.

### ТУГАН ТЕЛ

Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе
Җитсен иде һәрбер күңелгә,
Җилләр, сулар тавышы шикелле үк,
Үзләренең асыл телендә.

Атом көче, радио заманында
Күрсәм иде шуны мин тагын:
Ярдәмләшеп, телләр бер-берсендә
Тапса фәкать кардәш, туганын.

Бу дөньяның төсен, ямен, зәукын
Кем аркылы, ничек белдем мин?
Бишектә үк мине өйрәтүчем,
Туган телем – бәгърем, син ул, син!

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, тәрбиячем!
Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсен
Син аңлаттың миңа, туган телем,
Син өйрәттең миңа һәммәсен!

## ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА ҖЫРЛАР

### 1

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И безнең батыр телебез,
И безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

### 2

Тарихым истәлеге син,
Болгарым истәлеге.
Гасырлар аша үтелгән
Юлларым истәлеге.

Чишмәләр исән чагында,
Иделләр кибәмени?
Гасырлар күммәде сине,
Дәверләр күмәмени?

Иңгә-иң безнең теләкләр,
Кулга-кул уйларыбыз.
Якты язмышларга таба
Барасы юлларыбыз.

Син – минем тере тарихым,
Син – минем киләчәгем,
Тик синдә, газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем.

И телем, синдә нәфислек
Чишмәсе кибәрмени?
Гасырлар сиңа тимәде,
Дәверләр тиярмени?

* * *

Кайларда булса да минем
Дөньяга килгән җирем,
Иң газиз нәфис туган тел,
Син минем Туган илем.
Денем син, бәгърем, туган тел,
Күрәсең, шуңа күрә,
Башымны идерсәләр дә,
Йөрәгем аягүрә лә,
Йөрәгем аягүрә.

## *Һади Такташ*

*(1901–1931)*

Мордва Республикасының Торбеево районы Сыркыды авылында дөньяга килә.

Пешли[1] авылы мәдрәсәсендә укый.

Казан шәһәрендә вафат була.

### АВЫЗЛАРЫ, БОРЫННАРЫ ҖИМЕРЕЛГӘН СҮЗЛӘРНЕ ЯКЛАП

Кабыргасыз, йомшак урыс теле,
Ничек борсаң, шулай борыла
(Башка чарасы юк), –
Безнең агай-эне
Эләккән һәр урыс сүзенең
Кабыргасын тотып сындыра!
Сүз юк –
Урыс телен белү кирәк нәрсә.
Ләкин
Кирәклеген аның бутыйлар,
Татарларга, татар була торып,
Урысчалап доклад укыйлар.

Ответработниклар!
Бәлки,
Урыс теле шәп тел икәнлекне
Күрсәтүдер сезнең уегыз, –

[1] Моңа кадәр Пешлә дип өйрәнелә иде (Л.Р.Гайнанова төзәтмәсе).

Яхшы эш ул,
Тик шулай да, зинһар, куегыз!
«Ответ» дигән сүзнең «в»сын ашап,
«Әтбит» дигән булып йөрисез;
«Моя» белән «мой»ның муенын борып,
Үтерергә, ахры, телисез.
«Совсем» сүзен «чәпчим» чәпчеттегез,
Урыс аңламаслык иттегез;
Бу ни хәл бу, «әтбитработниклар»,
Бу нинди юл белән киттегез?!
Татар газетына урысчалап
Мәкаләләр язып бирәсез.
(Секретарьга кушып яздыруны
Сизмиләр дип, ахры, беләсез...)

---

Урыс теле инде урыс белән
Сөйләшергә, әйтик, яраса,
Татар теле ул бит татар белән
Аңлашырга ярый ләбаса...

## *Сибгат Хәким*

*(1911–1986)*

Татарстан Республикасының Әтнә районы Күлле Киме авылында туа.

Казан дәүләт педагогия институтында белем ала.

Татарстан Республикасының Г.Тукай, Россия Федерациясенең М.Горький исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты (1960, 1970), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1986).

Казанда вафат була.

### ТЕЛ ИЛ БЕЛӘН ИКӘН

Язмышым, рәхмәттән башка
Бер сүзем юк бу җиргә,
Мин риза-бәхил; колак сал
Минем соңгы гозергә.
Мин башка гозерләр белән
Сине бүтән йөдәтмәм.
Язмышым, үзең аердың,
Юк әткәм һәм юк әнкәм,
Юк җирдә башка шатлыгым.
Әйтче, мин кемнән, йә, ким?
Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим.

* * *

Күп уйландым Дуга төннәрендә:
Онытылырга мөмкин җан дуслар,
Туган телең искә төшә икән
Хәл ителгән чакта язмышлар.
Ул язмышлар уртасына керә, –
Таң вакыты булсын, булсын кич,
Сызып, телеп, күңел түрләреннән
Күтәрелә башлый моңсу хис.
Чишмәләре кушыла төрле яктан,
Чишмәләрдә кайный бөтен дәрт,
Артта таллар – татар хатыннары
Сөйләшәләр төсле лепердәп.
Сөйләшәләр төсле: бу арада
Балаларның никтер аз хаты...
Туган телем – минем әнкәйнең ул
Ризалыгы, соңгы васыяте,
Фатихасы булып яңгырады.
Моңландырган чагы күп аның.
Бикләмәде, чикләмәде телем,
Кырларына тикле Дуганың
Килде алып...

## «ТУКАЙ ДӘФТӘРЕ»ННӘН

Кайтамын туган ягыма
Елның бай вакытында;
Утырам Казан артында –
Телнең пайтәхетендә.

Утырам, тирә-юнемдә,
Янымда күп сабыйлар;
Миңа бу олы тәхетне
Калдырган Курсавилар.

Мәрҗани анда утырган,
Тукайлар булган шаһы;
Алар саклаган күк сакла –
Бер генә аның шарты.

## *Нәҗар Нәҗми*

*(1918–1999)*

Башкортстан Республикасының Дүртөйле районы Миңештте авылында туа.

Башкорт дәүләт педагогия институтында укый.

Башкортстан Республикасының С.Юлаев исемендәге Республика һәм Россия Федерациясенең М.Горький исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты (1972, 1982), Башкортстан Республикасының халык шагыйре (1992).

Уфада вафат була.

### ТАТАР ТЕЛЕ

Вы, прадеды наши, в недоле
мукою запудривши лик,
на мельнице русской смололи
заезжий татарский язык.

*Я.Смеляков*

Туган җирең – Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине?!
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс Тукай теле!

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире.
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең –
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле – дуслык теле.

## *Гамил Афзал*

*(1923–2003)*

Татарстан Республикасының Актаныш районы Такталачык авылында дөньяга килә.

Троицк шәһәрендәге Татар педагогия техникумында ике ел белем алганнан соң, авыру сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр була.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1977), Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1991).

Әлмәт шәһәрендә вафат була.

### АНА ТЕЛЕ

Һәркемгә дә иң газиз тел – ана теле,
Анда гына сабый чакның раушан гөле –
Кышкы кичтә әбиләрнең әкиятләре,
Әниләрнең бәллү җыры, бәллү көе.

Ана телем, сине өзелеп ярātканга,
Очам дисәк, безгә булдың канатлар да;
Дошман белән көрәшкәндә – үткен кылыч,
Балдай татлы – дуслар белән сайрашканда.

Күңелләрдән күңелләргә юл саласың,
Сусаганда эссе чүлдә, су табасың.
Алышларда арысланга тиңдәш итеп,
Тоткынлыкта тимер булып таш ярасың.

Җырларның да иң татлысы синдә генә,
Уйларның да иң яктысы синдә генә.
Туган илнең, туган телнең матурлыгы
Якты илһам бирми икән кемгә генә!

Кайчагында адашкандай булам да мин,
Уңны-сулны шәйләмичә егылам, димен.
Туган телем балкыта да барыр юлны,
Күз алдымда ярылып ята кыйблам минем.

* * *

Үткер сүз, тапкыр сүз – уй бинасы,
Тәмле сүз, татлы сүз – ил йоласы.
Тыңлап кына торса, ни буласы,
Фикерсез озын сүз – тел зинасы.

* * *

Хак сүз, нык сүз тамырларга үтә,
Тимер иман кебек була сүз;
Күп сөйләнгән сүзнең кадере китә,
Иске чүпрәк кебек уңа сүз.

* * *

Кешелегең, татарлыгың такы-токы,
Ана телен онытканның аты корсын.
Пәйгамбәр бул, тугыз телдә китап укы,
Өстәлеңдә иман булып Тукай торсын.

* * *

Телем барда үргә омтылырмын,
Күз өстендә торган каш кебек.
Телем бетсә, мин дә онытылырмын,
Күл төбенә төшкән таш кебек.

## СҮЗ

Сүз әйтергә тәвәккәллек кирәк,
Сүз йөрәккә ялкын үткәрә;
Сүз киптерә, төп башына терәп,
Сүз меңнәрне яуга күтәрә.
Сүз уйларны кайрый кайрак кебек,
Сүз сафларны ипли корычтай.
Сүз көрәшкә чыга байрак кебек,
Сүз дошманны кисә кылычтай.

## *Шәүкәт Галиев*

*(1928)*

Татарстан Республикасының Апас районы Олы Бакырчы авылында туа.

Казанда эшче яшьләрнең кичке мәктәбендә белем ала. Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премияләре лауреаты (1972, 1996), Г.-Х.Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом иясе (1982), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1995).

### ТУГАН ТЕЛЕМ

Әнкәм сөеп-сөеп әйткән,
Әткәм чөеп-чөеп әйткән,
Апам биеп-биеп әйткән
Матур сүзләр җанымдадыр!

Әбкәм сыйпап-сыйпап әйткән,
Бабам сыйлап-сыйлап әйткән,
Абзам сынап-сынап әйткән
Зирәк сүзләр аңымдадыр!

Бәет көйләп-көйләп әйткән,
Кыйсса сөйләп-сөйләп әйткән,
Такмак иләп-иләп әйткән
Гыйбрәт сүзләр намымдадыр!

Телгә тимә – аңга тимә,
Телгә тимә – канга тимә,
Телгә тимә – намга тимә,
Тимә, тимә – җанга тимә!

## ТУГАН ТЕЛ

Туган тел – иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма –
Туган телне онытма!

## *Гөлшат Зәйнашева*

*(1928–2005)*

Татарстан Республикасының Тукай районы Иске Теләнче авылында дөньяга килә.

Минзәлә педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогия институтында белем ала.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1991).

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТУГАН ТЕЛЕМ

Рухыбызда туган тел син,
Җаныбызда туган тел.
Ясалма, килмешәк түгел,
Каныбызда туган тел.

Рухыбызда туган тел син,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Борынгы бабабыз теле,
Болгар бабабыз теле.

Бишек җыры көйләгән тел,
Моңлы, ягымлы тел син.
Гашыйкларны таныштырган
Һәм кавыштырган тел син.

Зәңгәр күктәге кояш кебек
Якты нур сипкән тел син.
Халкыбызны иманлы иткән,
Шәфкатьле иткән тел син.

Рухыбызда туган тел син,
Җаныбызда туган тел.
Ясалма, килмешәк түгел,
Каныбызда туган тел!

## *Энҗе Мөэминова*

*(1929–2009)*

Татарстан Республикасының Әлмәт районы Яңа Кәшер авылында туа.

Казан дәүләт педагогия институтында ике ел белем алганнан соң, Ташкент педагогия институтына күчеп, укуын шунда тәмамлый.

Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1994), Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2005).

Әлмәт шәһәрендә вафат була.

### ТУГАН ТЕЛЕМ

Дөньяда иң-иң матур ил
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул – минем туган телем.

«Балам!» диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
«Әнием!» дип әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.

Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
«Туган ил» дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам!

## *Резеда Вәлиева*

*(1930)*

Башкортстан Республикасының Кыйгы районы Дүшәмбикә авылында туа.

Казан дәүләт университетында укый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1999).

### И ГАЗИЗ ТУГАН ТЕЛЕМ...

И туган тел, күкрәгемдә
Тибрәнгән тәүге сүзем,
Алда әле һаман көрәшләр –
Бирешмә, әй, бул түзем.

Юлларыңда нинди генә
Җил-давыллар күрмәдең,
Моабит тәмугына да
Түздең бит син, үлмәдең!

Күпме таландың, тапталдың,
Утлы мәхшәрдә калып;
Бирешмәдең, бәреп чыктың,
Таш диварларны ярып.

Һәм балкыттың бар дөньяга
Батырларның эзләрен,
Йөрәк каны белән язган
Соңгы васыять-сүзләрен.

Дошманнарга татар исемен
Пычратырга бирмәдең,
Факел итеп күтәрдең син
Каһарманнар йөрәген!..

Канлы көрәш утларында
Корычланган тел бит син,
Билен бирмәс, үлем белмәс
Батырларга тиң бит син.

Беләм, язмыш нинди генә
Ялкыннарга салмасын,
Авыр көрәш юлларында
Үз үрләрең яуларсың!

Һаман яуда, көрәштә син,
Сөекле сазым минем.
Инде үз туган җирeңдә
Яшәү даулаган көнең...
И газиз туган телем!

## ТУГАН ТЕЛ

Чагыладыр аңарда
Чишмәләрнең чыңы,
Чишмәләр буенда
Җырланган җыр моңы.

Иделем агышы,
Йөрәгем сагышы,
«Бәлли-бәү» көйләүче
Әнкәем тавышы.

Тибрәтеп күңелне
Агыладыр тын гына,
Әйтерсең асылы
Тылсымлы моң гына.

Шул тылсым – моң белән
Кергәнгә күңелгә,
Онытылмый туган тел,
Онытылмый гомергә...

## *Илдар Юзеев*

*(1933–2004)*

Башкортстан Республикасының Яңавыл районы Ямады авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт педагогия институтында белем ала, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1968, 1980), Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе (1979, 1983), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1993).

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТУКАЙ ТЕЛЕ

Җиде бабамнар көйләгән
шигырь һәм дога теле,
Мөхәммәтгариф мулла һәм
Бибимәмдүдә теле.
Юк, түгел бу читтән килгән
килмешәк – нәнкә теле,
Бу – татарның җаны иңгән
әткә һәм әнкә теле.
Безне олуг милләт иткән
гадәт һәм йола теле,
«Әнкәй» дигән сүзне көткән
Бибимәмдүдә теле.

Бу сүзем – шагыйрь әткәсе –
изге бер мулла теле,
Бибимәмдүдә баласы –
Апуш – Абдулла теле.
Җиһанда аз яшәп киткән
Мөхәммәтгариф теле,
Гасырларны иңләп үткән
шигърият, тарих теле.
Көзге җилләрне елаткан
Мөхәммәтгариф теле,
Мәктәп баласын җырлаткан
фән һәм мәгариф теле.
Туган тел аша ачылды
читтәге дөнья теле,
Анда дуслар бик аз иде,
инде бар дөнья тулы.
Милләтнең теле яшәсә,
сау булыр дәүләт, иле.
Һәр бала сөйсә Тукайча
үз телен, туган телен, –
Тукай теле, татар теле
булыр гел исән, тере!

## *Роберт Әхмәтҗанов*

*(1935–2008)*

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе район үзәгендә туа.

Казан дәүләт педагогия институтында укый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1995), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2001).

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТУГАН ТЕЛЕМ

Төрле телләр, бәхәсләшеп,
Ят итсәләр бер-берсен,
Бер чеметем тозга манып,
Икмәк ашыйм бер телем!

Телем – шул ук туган илем,
Җирдә телсез ил булмый.
Телен йоткан шамакайга
Тел күрсәтеп, тел булмый!

Татар – минем туган телем.
Туган телгә юк үлем!
Телең белән ачыла, халкым,
Чишмәдәй саф күңелең!..

Телем-телем киссәләр дә,
Яшәрсең, ана телем!
Телем минем – шул ук туфрак,
Каберемдә үскән гөлем!..

## МИН – ТУКУЧЫ

Сүзләр эрлим,
киләп сарам сүзләрдән;
сүз тәрәшлим,
керешләрен керештерәм,
эзен китерәм эзләргә.

Сүз җебеннән җырлар тукыйм.
Телем – җырлар станогы;
шүреләрем, сосаларым,
өлгеләрем, кысаларым –
туган телем осталыгы!

Биеп тора шүреләрем,
җемелдәтеп буяуларын:
яшел җебе – яшь көннәрем,
зәңгәр җебе – хыялларым,
кызыл җебе – шатлыкларым,
сары җебе – сагышларым...

Сүсләр түгел,
сүзләр талкыйм –
җилләр ала талкышларын...
Шигырьләрем – рух авазым,
сездә – уңыш-табышларым...

Сездә – ялгышларым!..

## *Зиннур Насыйбуллин*

*(1937–1986)*

Башкортстан Республикасының Нуриман районы Кече Теңкәш авылында туа.

Башкорт дәүләт университетында белем ала.

Казанда вафат була.

### ТУГАН ТЕЛ

Синдә – шатлык җиңеллеге,
Кайгылар авырлыгы,
Ата-бабам батырлыгы,
Аналар сабырлыгы.

Синдә – күңелләр киңлеге,
Туган җирем ямьнәре.
Синдә – илем иркенлеге,
Синдә – дөнья гамьнәре.

Югалтмыйсың, туган телем,
Сине югалтканны да.
Син алып чыктың дөньяга
Синнән баш тартканны да.

Сиңа тел тидергәннең дә
Телен син ачкан идең,
Ана булып бишегенең
Янына баскан идең;

Сиңа кырын караганның
Күзен син ачкан идең.

Рухыбыздан табылган тел,
Тагылган тел түгел син;
Тар юлларга тигәнәктәй
Сарылган тел түгел син.

Көлү теле, елау теле
Уртак, диярләр. Беләм.
Ләкин татарча елыйм мин,
Татар телендә көләм.

## *Бикә Рәхимова*

*(1939)*

Татарстан Республикасының Әлки районы Чуаш Кичүе авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында укый.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2009).

### ГАЗИЗ ТЕЛЕМ, ЯКИ ЧЫН ТАТАР ГАМӘЛЕ

Диңгез, дисәм, болын, дисәм,
Дисәм, кара урманым,
Бу, чынында, үз телемне –
Татар телен барлавым.

Чәчәк кебек кырлар, дисәм,
Чәчәк, дисәм ак карны –
Шулай матур атап әйткән
Башка берәр тел бармы?

Кызы чибәр, егете асыл,
Дип мактасам парларны...
Туган телдә чакрып алыйк,
Искә алыйк ярларны...

Газизем, дип, кадерлем, дип
Иркәләсәм баламны,
Бу, чынында, үз телемне –
Татар телен барлавым.

Шикәрем, балым, дисәм дә,
Бал тәмен тоям телдә.
Чын татар гамәле булыр –
Сөйләшик туган телдә!

Газиз телем – чиксез күгем,
Син диңгезем – хыялым,
Мәңгегә сине яшәтү –
Бердәнбер ихтыярым.

## СҮЗ ЛӘЗЗӘТЕ

Күкләрдән дә эзлим асыл сүзне,
Җир-сулардан табам энҗеләр.
Сүз ләззәте тәмле ширбәт кебек,
Күңелемә шуңа сеңделәр.

Актарылып чыккан вулкан кебек,
Урыныннан купкан таулардай,
Күңел фонтаннары бәргән чакта,
Халыкларны илгә даулардай

Көчләр иңә. Ике җилкәмә дә,
Рәхмәт фәрештәсе кунгандай.
Кояшлардан алып сүз күчерә
Безгә милли символ – тулган ай.

Сүз ләззәте бирә үзгә тәмнәр,
Затлы ашка охшаш, түгел дә...
Затлы сүзләр сайлап-сайлап кына,
И салыек, кардәш, күңелгә.

## *Ренат Харис*

*(1941)*

Ульянов өлкәсенең Богдашкино районы Зирекле Күл (Кәмә) авылында туа.

Казан дәүләт педагогия институтында белем ала.

Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Россия Федерациясенең Дәүләт премияләре лауреаты (1972, 1997, 2005), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1980), Каракалпак АССРның, Чуваш Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1980, 2002), Татарстан Республикасының халык шагыйре (2004).

### ТӨРКИ ТЕЛЛӘР

Төрки телләр шактый аерылышкан...
Сүзләр бер үк... Мәгънә – төрлерәк...
Күрше яшәсәк тә гомер бакый,
яшәгәнбез икән бик ерак.

Кардәшлекне истә тотсак та без,
аз йөрештек хәтта кирәктә;
былбылларыбыз да сирәк кунды
йөрәктәге төрки тирәккә.

Аерылганны аю ашар, диләр...
Татар телем, бик күп гасырлар
аю-бүреләрдән таланса да,
исән кала алды асылда.

Төрки халык әгәр беравыздан
әйтмәк булса Җирдә бөек сүз,
татар теле мәгъруур хорда яңрар –
Ул куәтле, дәртле, җылы, төз!

Без, төркиләр, бүген шактый төрле,
юкса бер үк ана имезде...
Ләкин туплый безне изге сөттән
телебезгә сеңгән игезлек.

* * *

Кем язса да, туган телен
мактап язар...
Һәм шул телдә кайчак язар
сап-сай әсәр...
Төссез әсәр телне хурлар,
ямен урлар.
Яхшы әсәр, яхшы улдай,
телне зурлар!

## *Рәдиф Гаташ*

*(1941)*

Башкортстан Республикасының Кушнаренко районы Марс авылында дөньяга килә.

Башкорт дәүләт университетында ике ел белем алганнан соң, Казан дәүләт университетына күчә һәм укуын шунда тәмамлый.

Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1982), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Татарстан Язучылар берлегенең Һ.Такташ, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты (2005, 2008).

### БЫЛБЫЛГА ЭНДӘШҮ

Кер әле, керче яныма:
Тәрәзәм ачык, былбыл!
Бүлмәмне тутыр моң белән –
Күңелнең кунагы бул.

Сөйләче: тиңсез җырыңның
Күпме ул гомер, яше?
Нинди ил, дәверләр гаме
Моңына күчеп яши?!

Үткәннәрдән киләчәккә
Тоташып сайрау өчен,
Кем бирде сиңа, нәни кош,
Тарихны саклау көчен?!

Ә нинди телдә сайравың?!
Борынгы әнкә телме?! –
Аңлыйбыз сине... югыйсә
Һәммәбез төрле-төрле.

Һәр халык үз моңын эзли,
Күңел тавышын таба:
Безне мәңгелеккә дәшкән
Вакытмы синдә ага?!

И былбыл фәне, син чорлар
Чынлыгы белән көчле!
Илаһи да, гади дә син,
Һава, су, икмәк төсле...

Бәһасез алтын мирас син!
Нәселеңә, варисыңа
Шундый ук сәләт килерме
Якты моң ярышында?

Югалтмасលармы соң моңны?
Сез – Бөек Былбыл иле,
Моң – гомумдәүләт байлыгы,
Ул – милли дәүләт теле!
Йотылу, бетү юк аңа –
Былбылстанга, димен...
Моңыннан язган теленнән,
Дененнән язар иде...

Халык тарихы – Әнкә тел! –
Моң теле икән – былбыл!
Гомер!
Шул тел сагында син
Мәңгелек гыйбрәт –
Моң бул!

## *Әнвәр Шәрипов*

*(1941)*

Татарстан Республикасының Баулы районы Кәрәкәшле авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында белем ала.

Татарстан Республикасының атказанган укытучысы (2005).

### ТУГАН ТЕЛЕМ

Әнкәм сөте белән йөрәгемә,
Тән-җаныма үтеп кердең син.
Гомер буе күңелемне назлап,
Тугры юлдаш булып йөрдең син.

И мөкатдәс әткәм-әнкәм теле!
Изге телем, газиз телем син!
Югалмассың, туган халкымны син
Ерак гасырларга илтерсең.

Иң беренче тапкыр «Ил-Җир» сүзен
Туган телемдә мин әйткәнмен.
Әлифбадан тәүге «Әни» сүзен
Укып, сөенеп, өйгә кайтканмын.

Туган телдә «Сөям» сүзе белән
Чәчәк атты яшьлек хисләрем.
Шушы телдә тәмләп мин сөйләшәм
Көндезләрен, иртә-кичләрен.

Гомер үтәр, соңгы сүземне дә
Мин әйтермен туган телемдә.
Онықларым чиста, матур итеп
Сөйләшерләр ана телемдә.

И мөкатдәс әткәм-әнкәм теле!
Изге телем, газиз телем син!
Югалмассың, туган халкымны син
Ерак гасырларга илтерсең.

## *Гәрәй Рәхим*

*(1941)*

Татарстан Республикасының Лениногорск районы Федотовка авылында туа.

Казан дәүләт университетында белем ала, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре (2007).

### СҮЗ ТӘМЕ

Сүзләр сүзгә ялгана да китә,
Ялгана да китә – могҗиза!
Кинәт шундый якты җөмлә туа –
Чаткылары чәчри йолдызга.

Күнегелгән көнең илаһи бер
Мизгел булып балкый кинәттән.
Талгын җанда кояш күтәрелә
Шагыйрь биргән җөмлә-бүләктән.

Язгы урман кебек яшь бу җөмлә,
Бөркеп тора аннан саф һава.
Күңелдә – дәрт, гүя чиләгеңә
Салкын кымыз өчен сөт ява.

Һай, сүз тәме! Һай, син татлы тамыр!
Яшәртәсең уйны, җаннарны.
Уйнатасың тәндә яңа каннар,
Алмаштырып иске каннарны.

Шигъри җөмлә! Сине табар өчен,
Күпме шагыйрь шаша, яскына.
Сине яклап, шагыйрь асыллары
Башын куя балта астына.

Бөек җөмлә балта астыннан да
Чәчрәп чыга, охшап йолдызга...
Төн... Тын булмә...
Сүзләр бер-берсенә
Ялгана да китә – могҗиза!

## *Рәшит Әхмәтҗанов*

*(1941–1995)*

Татарстан Республикасының Баулы районы Татар Кандызы авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында укый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1991).

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТАТАР ТЕЛЕ

Мин – халкыңның теле,
Сине эзләп,
Канга батып беткән хәтере.
Бәлки, сиңа «үлде» дигәннәрдер,
Мин – исән-сау, мин – бар, мин – тере!

Нигә, балам, юллар уртасында
Башмагыңа карап баш идең?
Чукынмадыңмәле? – Җиде бабаң
Васыятен тапшырыр идем.

Күзләреңә төшкән күләгәне
Таратыймчы диеп мин килсәм,
Кипкән иреneңдә ярылып яткан
Сүзләреңдә әле мин исән:

«И син, телем, әнкәм, җанкисәгем,
Истәлегем, исән көннәрем!
Сабый чакларымда бишегемне
Тирбәтергә нигә килмәдең?»

Мин коллыкта әле. Илемдә дә
Алтын сүзләремә юк кадер.
Дөньядагы исәннәрем белән
Исәнләшә алмыйм мин хәзер.

Мин – барыбер диңгез! Бөтенегез
Аягөсте басар, шауласам.
Әзләреңә энҗе-мәрҗән сибәм,
Дулкын бәрелгәндә, аумасаң.

Минем мәрҗәннәрдә җиде бабаң
Васыяте шулай җемелди.
Җем-җем иткән утка таба китсәң,
Әбиләрең шулай җеп эрли.

Нурларымны ятлар җыеп ала,
Капчыгына сала – кимеми.
Өзелмиләр, чуалмыйлар алар –
Безнекеләр шулай җан бирми!

Кил син, балам,
Кер син кочагыма,
Уйлый күрмә илдән китәргә.
Исән чакта – бүген исәнләшик,
Соң булуы мөмкин иртәгә.

Исәнләшик.
Мин – халкыңның теле,
Кылыч телгәләгән хәтере.
Сиңа мине «үлде» дигәннәрдер,
Мин – исән-сау, мин – бар, мин – тере!

* * *

И туган тел!
Сине Әнкә итеп
Йөрәгендә саклый бу халык.
Таралган ул... Әгәр син булмасаң,
Бетәр иде күптән югалып.

Югалмадың,
Югалтмадың безне –
Халык исән калган Син барга.
Бу дөньяга күзебезне ачтың,
Хакыбыз юк кабат йомарга.

Ләкин күпләр үз йортыннан куды
Бүген Сине – үзенең Әнкәсен.
Үз әнкәсен йорттан куган кеше,
Туган илем бар, дип әйтмәсен!
Әйтмәсен!..

## ЙӨРӘК БӘЙРӘМЕ

Бергәләп җырлыйк туган тел җырын,
Кечкенә чакта җырлаган кебек.
Һавада кояш, җирдә туган тел
Булмаса әгәр, зураймас идек.

И туган телем, Идел-ил җыры,
И әнкәм теле, тере изгелек!
Югалсам – таптың, янсам – син генә
Ирнемә сулар тигердең килеп.

Сөенеп җырлыйк туган тел җырын,
Онытканнарның бәгырен телеп.
Мин ятим түгел икән әле, дип,
Сабыйлар иртән уянсын көлеп.

Җырлаган әнкәм: дөньядан балам
Китмәсен, диеп, үземнән элек...
И туган телем, сиңа да шундый
Изге теләкләр тели Мәңгелек.

## *Равил Фәйзуллин*

*(1943)*

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында туа.

Казан дәүләт университетында белем ала.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1978), Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1999).

### МИНЕМ ТЕЛЕМ

Минем телем –
меңәрләгән ишләре күк,
тыйнак тел ул.
Гайрәтләнмәс, артык һаваланмас,
яңгырыйм дип кабаланмас,
җегәр чиген белер,
йөрер җирен...

Басынкы ул:
халыкара конгресслар,
парламентлар ачып йөрми,
акча, чеклар битенә менми.
Сугыш ачмыйлар минем телемдә,
капитуляция дә ясамыйлар...

Түзем тел ул.
Окопларда, төрмәләрдә, лагерьларда
атылса да, ысланса да, асылса да,
җиңү рухын җуймаган ул.
Гильотина өсләрендә
яшәү җырын җырлаган ул!

Минем телем –
меңәрләгән ишләре күк,
моңлы тел ул.
Үзенә җай, үзенә ятыш аның көе.
«Сак-Сок»лары, «Рамай»лары, «Сарман»нары,
«Гөлҗамал»ы, «Карурман»ы, «Әллүки»е...

Гавами ул,
бик гади ул.
Минем телдә иген үсә,
сөт парлана, җеп эрләнә,
нефть чыга, тире иләнә...
Туендыручылар,
киендерүчеләр дигәндә –
минем телем искә төшсен!

## ЯХШЫ СҮЗ

Әйт кенә
тәмле сүз –
иркәләр
күпме күз!

Әйт кенә
яхшы сүз –
һәркемдә
көләч йөз!

## ТУГАН ТЕЛ
## ТУРЫНДА БЕР ШИГЫРЬ

И кардәшем! Бер хаҗәтсез кайчак
телне шундый бозып сөйлисең!
Ил колагын хурлап, халкыңның
рухын рәнҗетәмен димисең!

Мескенләнмә, бакый гомер килгән
тел байлыгын итмә кадерсез.
Бер уйласаң, илаһи бит, изге –
Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз!

Һич мәртәбә түгел туган телдә
җиң очына карап сөйләшү.
Көчле, горур сөйләш! Кирәк икән,
хаким телләр торсын көнләшеп!

Иренмә син, туган, туган телнең
асыл байлыкларын ачарга.
Без ваемсыз булсак, чит-ят сүзләр
хәзинәңне әзер басарга!

Ана телне ватып-бозып сөйләп,
кешелегең генә төшә бит!
Корама тел, яман чир булып
яңа буыннарга күчә бит!

Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,
туган телең үги калмаса.
Җаның салып әйткән әткәң сүзен
синең аша балаң аңласа.

Мәгълүм: дөнья көтү, заман өчен
файдалырак телләр бары да...
Тик шунысы хак: фәкать туган телдә
иман иңә кеше җанына!

Киләчәкнең башы – бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнеңдә –
оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
матур итеп туган телеңдә!

* * *

Язуларга теркәлмәгән сүзләр күпме!
Чын, хак сүзләр,
ялган сүзләр,
йомшак сүзләр,
үткен сүзләр...
Очалар да кемнәрнеңдер ирененнән,
җил аларны сибеп йөри дөнья буйлап –
кыйтгалардан кыйтгаларга...
Югалалар?
Юк, югалмый, бетми алар!
(Сүз кадәр сүз ничек бетсен!)
Чыга алар йә таш булып,
Йә шыталар гөлләр булып...
Күрәләр дә бу хәлләрне
(Кешеләрне күрми димә!),
туа җирдә шытым –
йә изгелек,
йә яманлык...

## *Лена Шагыйрьҗан*

*(1945)*

Татарстан Республикасының Актаныш районы Пучы авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт педагогия институтында белем ала.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2000), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге премиясе лауреаты (2007).

### ТУГАН ТЕЛГӘ МӘДХИЯ

Әй син, телем, туган телем,
тамыр телем.
Җир астыннан тарих серен
табар телем...
Әй син, телем, рәхәт телем,
авыр телем.
Телне тешләп канатырлык
сабыр телем...
Синең белән рәхмәт укыйм,
теләк телим.
Җырга салып сине, милли
көйләр көйлим.
Табындагы икмәгем күк
телем-телем,
Табынам сиңа,
синсез бер тәм
тоймас телем...
Әй син, телем, айлы төнем,
якты көнем.

Әремнәрдән әче, балдан
татлы телем.
Сине саклап калыр өчен
күпме белем
кирәклеген аңладым мин,
белдем бүген...
Әткәм-әнкәм мирасы син
миңа күчкән.
Чишмә, үзе сусаганда,
сине эчкән...
Алдым сине,
күчтең төбем-тамырыма,
күчтең күзәнәкләремә,
карыныма.
Кердең аңга, яттың җанга,
сеңдең канга.
Һәр гөл белә үз исемен
син кушканга.
Җиһандагы һәрбер җисем,
һәрбер матдә,
Исемем бар, дип, гүя сиңа
рәхмәт әйтә.
Әй син, телем, батыр телем,
горур телем.
Җирдә йолдыз булып балкып
торыр телем.
Халкым теле, хак телем син,
йөрәк телем.
Киләчәгем өчен мәңге
кирәк телем!

## И ТЕЛЕМ СИН – ИДЕЛЕМ СИН!..

Иделемдә йөзгән ак балыктай,
и, Телемдә йөзеп карадым!..
Иңләп-буйлап, чумлап төбенәчә –
шигърем булды көймә-корабым...

И Телем син, иңле Иделем син,
синдә – назым, синдә – ярсуым.
Идел суы кебек эчтем сине,
сусанымны бастың, Җансуым!..

Сине яклап күпме җырлар яздым,
авыз суларымны корытып...
Җиде-ят бит белми синең тәмне,
карамаган килеш бер йотып...

Җир йөзендә күп лә су-дәрьялар,
тирәндерме алар, бик киңме...
И Телем син! Аһәң-аваз суым! –
синнән башка яшәү мөмкинме?!

* * *

...Мин авылда үскән бала. Телем
Җир-туфрактан шытып ачылган.
Авыл телем – авыр заманда да
Алтын орлык итеп чәчелгән.

Ташламадым, ташлар атсалар да,
Мин саклaдым аны, ул – мине.
Җитәкләшеп йөрдек. Тән сакчым да,
Җан сакчым да минем шул иде.

«Даһиларның» акцентына түзеп,
Минем «акцентымнан» көлделәр...
Еллар узгач күрдем, алар икән
Үз телләрен хәтта белмиләр.

## *Харрас Әюп*

*(1946–2008)*

Татарстан Республикасының Мөслим районы Түреш авылында туа.

Казан дәүләт университетында укый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1994), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2008).

Казанда вафат була.

### ТЕЛ АЧКЫЧЫ

Байлык-фәлән теләмәде безгә,
Кичерсәк тә гәрчә кыен чак –
Тел ачкычы тели иде әнкәй,
Бирәребез юлга җыенсак.

Җаныбызга салып шул ачкычны,
Сәфәрләргә киттек өйдән без.
Серле ачкыч булган икән лә ул,
Адашмадык, дисәм, нидән без?!

Ачып кердек күпме күңелләрне,
Серен белдек күпме бикләрнең!
Бәхетсезгә әйләнгәнен күрдек
Туган телен үги иткәннең.

Игелегең кабул итмәсләр күк,
Үзеңә кайтыр сыман – ук атсаң.
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Бу ачкычны әгәр югалтсаң.

Тел ачкычы тели иде әнкәй,
Бүтән тагын нәрсә теләсен?!
Туган телем!
Белгән бит ул минем,
Ни кылсам да, сиңа киләсем...

Байлыгымның олылыгын тоеп,
Ышанып керәм якты көнемә.
Дәверләрне ачар ачкычым бар –
Рәхмәт яусын туган телемә!

## *Нур Әхмәдиев*

*(1946)*

Татарстан Республикасының Азнакай районы Әсәй авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында укый, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1994).

### ТАТАР ТЕЛЕ

Ыргыттылар – төшеп ярылмадым,
Сындырдылар – сынып бетмәдем.
Чит иманнар оҗмах вәгъдә итте,
Татар тәмугыннан китмәдем.

Аяк асларында таптадылар,
Өзелмичә калды бер тамыр.
Мин дә бетсәм, сине татар итеп
Кем таныр да, синнән ни калыр?

Һәр халыкның теле бер генә ич,
Телсез калса, татар кем булыр?
Бу хурлыкка түзми, көпә-көндез
Зәңгәр күктән йолдыз егылыр.

Болгар каберләре, телгә килеп:
– Хыянәт вә хурлык, – диячәк.
Кол Галиләр, мәшһүр Сараилар
Әле тагын бер кат үләчәк!

Туасылар тумый калачаклар,
Яралгылар хәтта оялыр.
Теле бетсә, үзен татар диеп
Әйтә алыр тагын кем калыр?

Шуңа күрә мине саклагыз сез,
Намус саклагандай саклагыз.
«Поганый» дип, юк-юк, әйттермәгез,
Кылыч тотып хәтта яклагыз.

Кирәк икән, чыгып, рельсларга
Синең белән бергә ятармын.
И син, хуҗам, – мәнсез һәм ваемсыз,
Каһәрләнгән газиз татарым!..

## *Зөлфәт*

*(1947–2007)*

Татарстан Республикасының Мөслим районы Яңа Сәет авылында туа.

Казан дәүләт университетында белем ала, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2000).

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТУГАН ТЕЛ ХАКЫНДА

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: «Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: «Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр!

## ТЫЛСЫМ

Изсәләр дә, кылыч чапсалар да,
Юлыкса да юлда мең үткел,
Шигырьле тел –
фанилыкка бәйсез,
Үлемгә баш бирми андый тел.

Гамәлендә азат адәми зат –
Амин тотсын яки чукынсын.
Әмма сүздә шигъри куәт булса,
Ул сүз, димәк, үзе бер тылсым.

Шигъри сүзем минем – саф тылсымым –
Авыр чакта сезгә кагылсын.
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен безне бу тылсым!

Кардәшләрем! Сезнең җанда туган
Шигырьләрне әйтер сүз көчен
Ни өчендер Ходай миңа биргән –
Өлешемә тигән көмешем...

Дөньялыкта яман сүзләр булмый,
Яман әйтүчеләр булмаса –
Булсын сүзем
сүзләр чишмәсенә
Сүзләр чылтыратыр
Колаша.

Китсен сүзем фани бу дөньяга,
Йөрер юлы аның ак булсын –
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен безне бу тылсым...

## *Разил Вәлиев*

*(1947)*

Татарстан Республикасының Түбән Кама районы Ташлык авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында белем алганнан соң, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда укый.

Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1982, 2007), Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре (1990, 1997).

### ТУГАН ТЕЛДӘ ДӘШСӘМ ГЕНӘ...

*(җыр)*

Каршы ала туган якта
Тургай тавышы.
Бары тургай аңлый бугай
Минем сагышны.
Сайра, тургай, мәңге сайра, –
Аңлыйм телеңне.
Син сайрасаң, дөнья ямьле,
Яшәү күңелле.

Кушымта:

Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган җирем мине аңлар.

Сайрый тургай туган җирдә,
Шатлык түгелә.
Тургай җыры, тургай моңы
Минем күңелдә.
Җырлый бүген бөтен дөнья
Тургай телендә.
Мин кушылып җырлыйм аңа
Туган телемдә.

Кушымта.

## *Роберт Миңнуллин*

*(1948)*

Башкортстан Республикасының Илеш районы Нәҗәде авылында туа.

Казан дәүләт университетында белем ала.

Татарстан комсомолының М.Җәлил, Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премияләре, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1982, 1997, 1998), Г.-Х.Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом иясе (1992), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1998), Татарстан Республикасының халык шагыйре (2005).

### ТУГАН ТЕЛЕМӘ

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел – вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.

Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.

Әйтә алмыйм әле, ул җырлардан
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне!

## *Марсель Галиев*

*(1946)*

Татарстан Республикасының Азнакай районы Балтач авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында белем ала, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2006).

### ТУГАН ТЕЛ

Бөек тә син, боек та син,
И туган тел, туган тел,
Күп гамәлләр кылган тел!
Аргамаклар җилеп чапкан,
Былбыл сайрап кунган тел.

Елатасың, юатасың,
И туган тел, туган тел,
Кәүсәр сулар юган тел!
Әткәм нигез ташы куйган,
Әнкәм бишек корган тел.

Уйлатасың, уятасың,
И туган тел, туган тел,
Дәрья булып тулган тел!

Шанлы, данлы дәверләрнең
Хөкемдары булган тел.

Талымлы син, ягымлы син,
И туган тел, туган тел,
Халкым кебек уңган тел!
Күктән иңгән иман нурын
Мәңге саклый торган тел!

## *Мөхәммәт Мирза*

*(1952)*

Татарстан Республикасының Актаныш районы Чалманарат авылында туа.

Казан дәүләт мәдәният институтында белем ала.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2007).

### И ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, тыелган тел,
Шаһгалиләр – зобанилар
Кулы белән буылган тел,
«Бисмилла»сыз суелган тел.

Явыз Иван – явыз патша
Шомпол басып көйдергән тел.
Чукындырган чакларында
Таралышып сибелгән тел.

И милләтем, нишләттеләр, –
Таңнан базда эшләттеләр;
Баш күтәреп багыйм дисәң,
Сугып телең тешләттеләр.

Илсез калып, телсез калып,
Яши алсын нинди халык?!

## *Нияз Акмал*

*(1954–2007)*

Татарстан Республикасының Сарман районы Каташ-Каран авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында укый.

Татарстан Язучылар берлегенең һәм «Татнефть» Ачык акционерлык җәмгыятенең С.Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты (2006).

Казан шәһәрендә вафат була.

### ТУГАН ТЕЛ

Ул мине мәхрүм итмәгән
Моңнарыннан,
                    җырыннан.
Мин карында чагымда ук
Аккан ул тамырымнан.

Иркәли алмас идем мин
Җирнең иң иркә гөлен,
Белмәсәм Туган телемне,
Булмаса Туган телем.

Шатлана белмәс идем мин,
Кайгыра белмәс идем,
Ак белән караны хәтта
Аера белмәс идем.

Аера белмәс идем мин
Дөньяның көнен,
                    төнен,

Белмәсәм Туган телемне,
Булмаса Туган телем.

И әнкәй!
Күктәге йолдыз!
И әткәй!
Җирдәге таң!
Син, Сөйгән яр!
Син, Табигать!
Син, Шигърият!
Син, Ватан!

Башка телләрдә әйталмас,
Аңлата алмас сүзне
Туган телемдә әйтеп, мин
Иркәли алам сезне!

Ул мине мәхрүм итмәгән –
Ул мине эзләп тапкан:
Мин карында чагымда ук
Тамырларымнан аккан!..

## ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА

Туган телдә һәрбер хисне
Җөмләгә төреп була.
Әйтергә теләгәнеңне
Әйтеп бетереп була.

Туган телдә тик бер хисне
Җөмләгә төреп булмый:
Аны ничек яратканны
Әйтеп бетереп булмый...

## *Сөләйман*

*(1955)*

Чуваш Республикасының Батыр районы Кызыл Чишмә авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетының механика-математика факультетын тәмамлый.

### ТАШЪЯЗМАЛАР

*(өзек)*

...Сөт имешкән һәмдәмемдер[1], кан энисемдер телем,
Җан биреп күнмәм хәрим[2] вә асылдан тәгърибенә[3].

*Дәрдемәнд*

Аккош кала аккош булып,
Канатлары чатнап сынып
Ятканда да дулкын кочып.
Тел бит ул – җан, тел бит ул – моң,
Үксер дөнья, тел югалса,
Соң булыр, соң...

Телсез – милләт, денсез – мәчет булмас,
Телсез – милләт шытмас яшьләрдә.
Килер заман, терсәк тешләр идең,
Терсәгең дә булмас тешләргә!

---

[1] *Һәмдәм* – кардәш.
[2] *Хәрим* – «изге йорт» мәгънәсендә.
[3] *Тәгъриб* – сөрелү, читләштерелү.

И туган тел, и асыл тел,
Яклауга син мохтаҗ –
Иң бөек яд,
Иң затлы таҗ,
Мәңгелек хаҗ.

Татар телен күмер итсә күңел,
Онытымда булса телгә чик,
«Татар» диеп эндәшмәгез миңа,
Ышанмагыз миңа мишәр дип.

Татар теле үги бала булып
Кукрәгендә үксеп ятканда,
Килешәме «тылмач кирәкми» дип
Дөяләнеп йөрү татарга.

Тылмач кирәк үз телеңнән, татар,
Күңелеңдә «кырылл» тамгасы,
Татар телен ваклап-күпләп сата
Читләр түгел, татар баласы.

Нигә, Тәңре,
        төрки телнең биләве аһ-зардан?
Ни дип, Тәңре, син шул телне
        бирдең икән мин татарга?
Әллә берчак булдымы төрк үз теленә лаек?
Ышандыңмы, бу милләттә өмет-куәт тоеп?
Юк, ялгышмас бөек Тәңре,
Түкмәс мәрҗән җилгә!

Тәңре биргән илаһи тел
Яшәр азат илдә,
Яшәр иңгән җирдә,
Яшәр, татар, синдә!
...Ышанасым килә, ышанасым килә.

Булган җаның салып түбәтәйгә,
Тапсаң үзең эзләп әҗәлең,
Татар, сине жәлләп яшем чыкмас,
Татар теле булыр иң жәле!
Күмелсәң дә – үзең, күмдерсәң дә,
Тик үзеңдә моңа сәбәп бит.
Ә тел – изге,
Язмыш: «Бәхәс!» – дисә,
Татар теле әйтер: «Ядәч!» – дип.

## КЕМ СОҢ ҖАЙЛАР ТЕЛНЕҢ ҖАНЫН...

Чәбәләнгән телем кат-кат,
Йолкып-тартып тетмәгез,
Үрмәләр өчен үрләргә,
Телне аркан итмәгез...
Чәбәләнгән телем кат-кат...

Чәбәләнгән татар теле,
Кем соң үрер җаена?
Кем соң җайлар телнең җанын
Телнең үз уңаена?..
Кем соң җайлар телнең җанын...

## *Галимҗан Гыйльманов*

*(1957)*

Башкортстан Республикасының Дүртөйле районы Әсән авылында туа.

Казан дәүләт университетында белем ала.

Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2002), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2003).

### ТУГАН ТЕЛ

Миндә бер кыйммәт әйбер бар,
Күңел кебек изге ул.
Татар өчен – ачы язмыш,
Иман өчен – күзгә ул!

Миндә бер кыйммәт әйбер бар,
Иң кирәкле әйбер ул.
Өметтән дә өметлерәк,
Хыялдан да өлгер ул!

Онытырмый үткәннәрне,
Саклап тора хәтерне.
Кайчагында... дуслардан да,
Туганнан да кадерле!

Миндә бер кыйммәт әйбер бар,
Бәясен беркем белми.
Аны рәнҗеткән кешеләр
Яшәүнең күркен белми...

Миндә бер кыйммәт әйбер бар,
Әйтмәсәм дә беләсез...
Шуның өчен туасыз сез,
Шуның өчен... үләсез!..

Онытырмый моң-сагышны,
Гел шатлыктан торса да.
Канатлары – диңгезләрдә,
Тукайлары – Арчада!

Миндә бер кыйммәт әйбер бар,
«Миңа да бир», – димәгез.
Җан-бәгыремне алыгыз,
Туган телгә тимәгез!

## ТЕЛ УЛ – БАЙЛЫК

Тел ул – байлык. Калдыр гына,
Урлыйм дип, бер карак тора.
Читнекенә үрелсәң дә,
Җанга үтеп карап тора...

Тел ул – байлык. Ул ярата
Ил кадерен белгәннәрне.
Җан-рухы ул, гомрен биреп,
Шул ил өчен үлгәннәрнең.

Тел ул – байлык. Милләт белән
Бергә туа, бергә үлә.
Юк, үлми ул, язмыш булып
Мәңгелеккә җиргә килә.

## *Газинур Морат*

*(1959)*

Татарстан Республикасының Кукмара районы Зур Сәрдек авылында туа.

Казан дәүләт университетында белем ала.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Республика яшьләр оешмасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты (2007).

### ТУГАН ТЕЛ

Әткәң-әнкәң телен белсәң,
Адашмассың кайда да...
Туган телемдә эндәшәм
Кояшка да, Айга да.

Туган телемдә аңлашам
Үткән, бүгенем белән.
...Әлифбамны дога итеп
Укыймын күңелемнән.

Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була,
Әнкәй кебек – бер генә.

## *Илсөяр Иксанова*

*(1966)*

Татарстан Республикасының Лаеш районы Татар Сараланы авылында дөньяга килә.

Казан дәүләт университетында белем ала.

Татарстан Язучылар берлегенең һәм «Татнефть» Ачык акционерлык җәмгыятенең С.Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты (2006).

### ТУГАН ТЕЛЕМӘ

Туган телем, газиз телем, син – үз телем.
Синдә – фәһем,
Синдә – гыйрфан,
Синдә – гыйлем,
Авазлары ерак-ерак бабамнарның.
Ишетсеннәр иде шуны балаларым!

Мең аһәңле дәрьяларның бер дулкыны,
Саклап тора йотам диеп мең упкыны.
Аксаң иде упкыннарга йотылмыйча,
Башка дулкын-агымнарга кушылмыйча.

Туган телем, газиз телем, син – үз телем.
Синдә даны,
Синдә аһы ерак Илнең.
Авазы син күңелдәге Илебезнең –
Офыклардан офыкларга җиребезнең.

Язсалар да нинди генә имлаларда,
Үз аһәңең,
Үз агымың дәрьяларда.
Югалтмыйча саф моң тулы тавышыңны,
Телим тере дулкын булып агышыңны!

## *Ленар Шәех*

*(1982)*

Татарстан Республикасының Актаныш районы Тактала-чык авылында туа.

Минзәлә педагогия көллиятен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетында белем ала.

### САЛА ТЕЛЕ

Кала теле түгелсең син –
Сала теле,
И бүленмәс һәм сер бирмәс
Ана телем.

Авыл саклый синең тирән
Тамырыңны.
Ә шәһәрдә... «Явыз Иван»
Ябырылды.

Сабыйларның урыс теле
Кочагында.
Кара бөркет үз нотыгын
Куша монда.

Ялгыз калган Робинзондай
Бүген хәлең.
Кая синең горурлыгың
Һәм мөнбәрең?..

Кая синең күкрәк киереп
Йөргән чагың?..
Кая синең төркилегең?..
Кая чаңың?..

...«Әннә», – диеп ачылмаса
Сабый теле,
Киләчәктә кем аңлар соң,
Телем, сине?..

## ЭЧТӘЛЕК

***Йосыф Баласагунлы*** . . . . . . . . . . 3
Котадгу белек . . . . . . . . . . 3

***Мөхәммәдьяр*** . . . . . . . . . . 4
Нуры содур . . . . . . . . . . 4

***Дәрдемәнд*** . . . . . . . . . . 5
«Кил, өйрән, и туган, бер башка телне...» . . . . . . . . . . 5
«Урысча күп сүзең, азы татарча...» . . . . . . . . . . 5
«Урамнан һәм базардан чүплә сүзне...» . . . . . . . . . . 5

***Сәгыйть Рәмиев*** . . . . . . . . . . 6
Сүзем һәм үзем . . . . . . . . . . 6

***Мәҗит Гафури*** . . . . . . . . . . 7
Ана теле . . . . . . . . . . 7

***Миргазиз Укмаси*** . . . . . . . . . . 8
Милли тел . . . . . . . . . . 8

***Габдулла Тукай*** . . . . . . . . . . 9
Туган тел . . . . . . . . . . 9

***Хәсән Туфан*** . . . . . . . . . . 10
Туган тел . . . . . . . . . . 10
Туган тел турында җырлар . . . . . . . . . . 11
«Кайларда булса да минем...» . . . . . . . . . . 12

***Һади Такташ*** . . . . . . . . . . 13
Авызлары, борыннары җимерелгән сүзләрне яклап . . . . . . . . . . 13

***Сибгат Хәким*** . . . . . . . . . . 15
Тел ил белән икән . . . . . . . . . . 15
«Күп уйландым Дуга төннәрендә...» . . . . . . . . . . 16
«Тукай дәфтәре»ннән . . . . . . . . . . 17

***Наҗар Нәҗми*** . . . . . . . . . . 18
Татар теле . . . . . . . . . . 18

*Гамил Афзал* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Ана теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Үткер сүз, тапкыр сүз – уй бинасы...» . . . . . . . . . . . . . . . . 21
«Хак сүз, нык сүз тамырларга үтә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
«Кешелегең, татарлыгың такы-токы...» . . . . . . . . . . . . . . . . 21
«Телем барда үргә омтылырмын...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22

*Шәүкәт Галиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24

*Гөлшат Зәйнашева* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25

*Энҗе Мөэминова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27

*Резеда Вәлиева* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
И газиз туган телем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

*Илдар Юзеев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Тукай теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32

*Роберт Әхмәтҗанов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Мин – тукучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35

*Зиннур Насыйбуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36

*Бикә Рәхимова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Газиз телем, яки чын татар гамәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Сүз ләззәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40

*Ренат Харис* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Төрки телләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
«Кем язса да, туган телен мактап язар...» . . . . . . . . . . . . . . 42

*Рәдиф Гаташ* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Былбылга эндәшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

*Әнвәр Шәрипов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46

*Гәрәй Рәхим* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Сүз тәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

*Рәшит Әхмәтҗанов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Татар теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
«И туган тел!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Йөрәк бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53

*Равил Фәйзуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Минем телем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Яхшы сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Туган тел турында бер шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
«Язуларга теркәлмәгән сүзләр күпме!..» . . . . . . . . . . 58

*Лена Шагыйрьҗан* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Туган телгә мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
И Телем син – Иделем син!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«...Мин авылда үскән бала...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62

*Харрас Әюп* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Тел ачкычы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

*Нур Әхмәдиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Татар теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

*Зөлфәт* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Туган тел хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Тылсым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68

*Разил Вәлиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Туган телдә дәшсәм генә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70

*Роберт Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Туган телемә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

*Марсель Галиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

*Мөхәммәт Мирза* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
И туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76

*Нияз Акмал* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Туган тел турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

*Сөләйман* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Ташъязмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Кем соң җайлар телнең җанын... . . . . . . . . . . . . . . . . 83

*Галимҗан Гыйльманов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Тел ул – байлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86

*Газинур Морат* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

*Илсөяр Иксанова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Туган телемә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88

*Ленар Шәех* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Сала теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

Литературно-художественное издание

Для детей среднего и старшего школьного возраста

**ДАР РЕЧИ**

Составитель ***Калимуллина*** *Эльвира Тальгатовна*

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен

**ТЕЛ АЧКЫЧЫ**

Төзүчесе ***Кәлимуллина*** *Эльвира Тәлгать кызы*

Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2010.
Форматы 70´108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 4,2.
Тиражы 2000 д. Заказ О-1904.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.